Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы карары

№ 3 2020 ел., 28 октябрь

«Аксубай муниципаль районы Емелькино
авыл җирлегенең авылында Иске Чуаш Адамы
гражданнарның үзара салым акчаларын кертү
һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Емелькино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Чуаш Адамы авылы, Тау урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында 2020 елның 6 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Иске Чуаш Адамы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге Иске Чуаш Адамы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзсалым кертергә.

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- торак пункт чикләрендәге урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү);
- вак таш капламлы юл полотносы урнаштыру (вак таш сатып алу, ЩПС; эш өчен түләү - грунт күтәрү, вак таш салу, ЩПС)

2. Әлеге кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыру өчен товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.
- күл ярларын ныгыту (эшләр өчен түләү );
- буа ярларын ныгыту ( эшләр өчен түләү);

3.КККНЫ җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыгы төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« РИЗА »                                   «КАРШЫ».

3. Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән карар игълан итәргә: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә

Аксубай муниципаль районының
Емелькино авыл җирлеге башлыгы:                Н.И. Михайлова